**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлеге Советы КАРАРЫ**

**2018 елның «02» августы** **№ 89**

**«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясы, «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең 88, 89, 90 статьялары нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проектын (1 нче кушымта) хупларга.
2. «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында карар проекты хакында» Кама Тамагы муниципаль районы Советы карарына гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен» 2 нче кушымта нигезендә расларга.
3. «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү буенча 2018 елның 28 августына Кече Салтык авылы мәдәният йорты бинасында гавами тыңлаулар билгеләргә. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлеге Советы карары белән расланган гавами тыңлаулар уздыру тәртибе нигезендә гавами тыңлаулар уздырырга.
4. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Кече Салтык авылы, Бакый Урманче ур., 9, Мәдәният йорты бинасы; Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Кече Мәрәтхуҗа авылы, Вахитов ур., 9 йорт һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга. ,

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлеге башлыгы,  Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлеге Советы рәисе А.Г.Җиһаншин**